ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИХАЙЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ LIV СЕССИЯСЕ

**К А Р А Р № 20**

Михайловка « 24» декабрь 2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советының 2018 елның «26» ноябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 нче бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советының 2018 елның **«26» ноябрендәге** «Физик затлар милкенә салым турында» 31 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент:

торак йортларга, торак йортлар өлешләренә, фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә;

мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, төгәлләнмәгән төзелеш объектларына;

составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплексларга;

гаражлар һәм машина урыннарына, шул исәптән әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннарга;

һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык каралтылары яки корылмаларга;

2) 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;

2 процент:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына.

3) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе, Р.Х. Исламов